**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮҢГӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**СОВЕТ КУНГЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422008 Республика Татарстан Атнинский район д. Нижние Шаши. Тел. 3-60-38

# КАРАР

11 ноябрь 2022 ел № 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар чыгарам:**

1. 2022 елның 25 нче ноябренә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенынын үткәрү вакыты – 25 ноябрь 2022 ел 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
  үткәрү урыны – Югары Шашы авылы, Гагарин урамы, балалар уен мәйданчыгы каршында;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 19 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Шашы авылы, Молодежная урамы, 68 нче йорт;
- сайлау хокукына ия булган Югары Шашы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Югары Шашы торак пункты халкына гражданнар җыены турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы

студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- янгын гидранты һәм төзелеш материаллары сатып алу, урнаштыру, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү;
-урам утларын яктырту максатыннан лампалар,автоматлар, җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;
 - авыл территориясен төзекләндерү, хезмәт өчен түләү (чүп үләннәрен чабу һәм чистарту);
 - Гагарин урамы, 1 нче йорт каршындагы чокырны киртә белән әйләндереп алу. (төзелеш материаллары  сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү);
 - урам юлларындагы чокырларны ямау (вак таш сатып алу, җәю һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү)

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә диган
мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

“РИЗА” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Түбән Шашы авылы, Яшьләр урамы 68 нче йорт адресы буенча стендка урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күңгәр авыл җилеге Советы
5 нче округ депутаты: Р.Х.Абдуллин